СОГЛАСОВАНО
Старший воспитатель МБДОУ
« Детский сад№ 26 комбинированного
вида» «АБВГДейка»
________ Л.М.Масленкова
«31»___08_____ 2023 год
Рассмотрено на педсовете
протокол № 1 от 31.08 2023 г.

УТВЕРЖДАЮ
Заведующий МБДОУ
«Детский сад№ 26комбинированного
вида «АБВГДейка»
________ Л.Н.Ильина
«__»___09_____ 2023 год

**Рабочая программа воспитателя по обучению детей дошкольного возроста родному (татарскому) языку муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад № 26 комбинированного вида «АБВГДейка»**

на 2023-2024 учебный год

Воспитатель по обучению детей татарскому языку Закирова Эльмира Рауфатовна

г.Чистополь
2023 год

**ЭЧТӘЛЕК.**


| | |
|---|---|
| 1.Аңлатмалы язу. | 3 |
| 2.Белем бирү эшчәнлеге планнары | 7 |
| 2.1.Беренче кече яштәге балалар (2-3 яшь) | 7 |
| 2.2.Беренче кече яштәге балалар (2-3 яшь) | 27 |
| 3. Педагогик тикшерү буенча киңәшләр | 40 |
| 4. Файдаланган әдәбият. | 46 |

**Балалар бакчасында татар балаларына ана теле өйрәтү программасы**

**Аңлатма язуы**

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәну һәм үстерә буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкечә милли белем биру өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм курсәту масьәләләре. Элеге проблемаларның бер өлеше "Туган телдә сөйлашобез" өйрәту-методик комплектары ярдәмендә чишелә. Тәкьдим ителгән эсбап - татар балаларын туган телгә өйрәту, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Анын теп максаты ана теленда балаларның дөрес эм яхшы телдән сөйләмен формалаштыру. Кече яшьтән үк баланың сөйләмен үстерү аның аралашу, танып белу, эхлакый һәм рухи юнәлешләр нигезен билгели.

Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын устеру Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрату, сөйлам үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм "Туган телдә сөйлэшабез" дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкдим ителә. "Туган телдә сөйлаэшәбе:"дип исемләнгән методик комплект икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектны теп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрату булса, төп узенчәлеге - тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйлаәм үстерү, тел һәм сөйлам күренешләрен анлау(тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтудә башлангыч роль уйный.

*Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы* мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйлам эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйратү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпка алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешлерне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игьтибар узгенә алына. Балаларның сөйләмен үстерү "Кроха"программасында (Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева һ.б.) күрсәтелгән, түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелә:

I. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белен турыдан туры таныштыру.

1. Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.
2. Предметлы деньябелән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, узлеклэре, эш-хәрәкәтләре).
3. Социаль күренешләр (үзен, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру.

П. Образлы уенчыклар, пластик художестволы образлар аша тирә-юнь белән таныштыру.

1. Уенчыклар карау.
2. "Тылсымлы капчык", "Бу өйдә кем (нәрсә) яши?" дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.
3. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.
4. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерак төркемнәргә булеп).

Ш. Художестволы картиналары аша (живописный, графический художественный образ) (буяулар һ буяусыз ясалган образлар (графика) әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Өстәлгә куела торган кечкенә картиналарны, китаптагы иллюстрацияләрне, стенадагы картиналарны карау.
2. "Җанлы" кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

IV. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Матур әдәбият, юаткычлар, шигырьләр, әкиятләр, хикәялар уку.
2. Тәрбияче белән бергә кыска гади әкиятләрнең эчтәлеген сөйлаү.

V. Курсәтмәлелектән башка тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү.

1. Курсәтмәлелектән башка һәм ситуциядән тыш тәрбияченең сөйләве.
2. Балалар белән әнгәмәләр һәм сөйләшүләр (тәҗрибәдән чыгып, күзәтүләрдән соң).

Методик әсбапта танып белү, коммуникация, матур әдәбият белән таныштыру кебек өч белем биру өлкәсе карала. Нәниләр эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезенда бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күзда тота. Болар - "Балалар бакчасы", "Күз", "Мин дөньяның бер кешесе", "Минем әйләнә-тирәм", "Кыш", "Яңа ел бәйрәме", "Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр", "Халык иҗаты", "Яз", "Жәй". Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг уткәрелә. Мониторинг нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан"Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем биру программасы" нигезендә төзелгән. Авторлар эшчәнлек конспектлары язганда үстерелешле өйрәтү, өйрәтү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык,
балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпк алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таяналар. Өйрәтү-тәрбия процессы балаларның "якындагы үсеш зонасында" (Л.С. Выготский) бара. Бу процессны әйдәп баручылар – тәрбиячеләр.

*Өченче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.* Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар, "куян булып сикерәләр ,"кошлар булып очалар", җим чүплиләр", "аю кебек алпан-тилпән йөриләр", "әтәч булып кычкыралар" һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.

Нәниләр белән эшләгәндә "Жанлы картиналар"куллану зур урын алып тора. "Жанлы картиналар"- тышкы кыяфәтләрен көтмәгәндә үзгәртәләр һәм шуның белән балаларның игьтибарын жәлеп итәлр. Алар эчтәлеге буенча ике-өч төрле эшчәнлек өчен кулланыла ала. Мондый очракта эшчәнлекнең аерым эпизодларын үзгәртергә кирәк. Мәсәлән, катнашучыларның санын кыскартырга яки арттырырга,

яңа элементлар кертергә мемкин. "Жанлы картиналар"ны темалар буенча сайлау мөһим: урам, йорт һәм кыргый хайваннар, кошлар, кибет һ.б. белән таныштыру.

Балаларны активлаштыру балаларның җаваплары конкретлаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны, хәрәкәтләрне кабатлату максаты белән эшләнә.

Тәрбияче балаларга гомуми сораулар белән мөрәҗәгать итә, барлык балаларга да бирелгән сорауны кечкенә бала үзена бирелгән дип кабул итми, шуна күрә тәрбиячегә соравын конкретлаштырырга кирәк (- Балалар, алма нинди төстә? - Әмир, алма нинди төстә? - Гузәл, алма нинди төстә? - Балалар, минем янга килегез әле. - Марат, син дә кил әле. -Алсу, син дә кил.).

*Өченче яшьтәге балаларныкң сөйләм үсеше үзенчәлекләре*

Өченче яшьтәге балаларның сөйләм үсешенәа мөһим үзгәрешләр бара. Танып белу сферасы камилләшә, сөйләм функцияләре арта. Сөйләм зурлар белән генә түтел, ә балаларның бер-берсе белән аралашу чарасы да булып тора.

Сөйләмне үзләштереп, бала предметларны гына түгел, ә сүзләргә, фразаларга да игьтибар итә башлый. Ул зурларның инструкциясен, кушкан, катлаулырак йомышларны да ишетә, кабул итә һәм ути ала. Бу яшьта сүзлек коммуникатив функциясе белән берлектә гомумиләштерү функциясенең дә камилләшүе дәвам итә. Балаларның сөйләмен формалаштыруда кабул итүнең әһәмияте зур. Бу яшьтә әйләнә-тирә дөньяны сенсор танып белү өстенлекле урын алып тора. Баланың күзаллаулар запасы арта һәм һәр нәрсәне бала сүзләрбелән белдерә башлый. Бу үз чиратында сузлек күләме артуга китера. 2 яшьтә бала сүзлегенда 270-300 суз 2,5 яшьта 400-500 сүз булса, 3 яшьтә 1000-1500 сүзгү житә. Балалар яңа сүзләрне генә тугел, ә сөйләм әйләнмәләрен да бик тиз отып алалар һәм кабатлый башлыйлар.

Балалар сөйләмендә бәйлек сүзләр дә очрый, сыйфат һәм рәвешләрнең саны арта. Ел ахырына балалар үз сөйләмнәрендә сыйфат фигыльдән һәм хәл фигыльдән башка барлык сүз төркемнәрен дә кулланалар. Болар барысы да балага үз фикерен формалаштырырга һәм җөмләләрдә белдерергә булышлык итәләр. Балалар кушма җәенке жөмләләрдән дә файдаланалар. Кече яшьтәге балалар нәрсә кирәген, нәрсә күргәннәрен һәм ишеткәннәрен әйләнә-тирәдәгеләргә ачык итеп аңлата беләләр. Булган тәҗрибәләренә нигезләнеп, өлкәннәр әйткән
фразадагы һәр аерым сүзне аңлый һәм хәтерендә калдыра.

Сөйләмнең коммуникатив функциясе камилләшә. Бала диалоглы сөйламне үзләштерә башлый. Кече мәктәпкәчә яшь чорында диалоглы сөйләм сөйләмдә аралашуның төп формасы булып тора. Үз фикерләрен теләп белдерергә өйрәнә. Өченче яшь ахырына балаларкуп сораулар белән мөрәҗәгать итәләр, бу аларның сөйләм һәм фикерләү үсеше турында әйтә. Ике яшьтән соң баланың яшьтәшләре белән аралашу теләге арта. Фонетик яктан караганда әле баланың сөйләме камил түтел. Өч яшькә туган телнең барлык авазларын кабул итсә дә, аларны бик дерес итеп әйтә алмыйлар.

Өченче яшьтәге бала аның белән аралашканда зурларның нәрсә турында сөйләвен яхшы аңлыйлар. Алар белән уткән һәм киләчәк турында да сөйләшергә була. Сөйләмнең актив булмаган формасы барлыкка килә. Балалар әдәби әсәрләрне, экиятларне, зурлар сөйләганн тыңлыйлар һәм аңлыйлар.

Кабул иткән нәрсәләрен бала үз теләге белән сөйләмдә чагылдырырга омтыла (сөйли, эчтәлеген сөйли). Тасвирый сөйләм һәм монологлы сөйләм формалаша. Болар барысы да баланың күзаллаулары киңәюе, аның мөстәкыйльлеге һәм хыял итүе үсеше белән бәйле. Бу яшь чоры сүз иҗаты үсеше өчен башлангыч булып тора. Ул баланың хисләрен, кичерешләрен ачык чагылдыра

Баланың сөйләмендә узенең төрле хисләрен, кичерешләрен ачык итеп чагылдыра белүе нигезендә ел ахырына сөйләм тагын сәнгатьлерәк була башлый. Болар барысы да аның шахес үсешенә зур йогынты ясый. Сүзлек эше, сөйләмнең грамматик ягы, аваз культурасы, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык ижаты белән таныштыру өстендә эшләү кебек бурычларны максатчан чишкәндә генә баланың сөйләм үсешендә унышларга ирешергә мөмкин.

***Икенче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы, сөйләм үсеше үзенчәлекләре***

Эшчәнлек төрләренда сөйләм үсешенең *сүзлек эше,сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сәйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* бурычлары хәл ителә.

Балалар белән эшләү процессында сүзлек эше зур урын ала. Сүзлек эше- бәйләнешле сөйләм нигезе. Балалар бакчасында сузлек эшенең өч бурычы чишелә:

1. Иң беренче чиратта, гомуми кулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларнын төп билгеләрен, сыйфатларын, алар белән эш-хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.
2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйту үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.
3. Сүзлекне активлаштыру.

*Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның* төп шарты – тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксик ягын, сүзъясалу ысулларын үзләштеру буенча үткәрелә торган күнегүләр.

*Аваз культурасы тәрбияләү* буенча эш аның сөйләм сульшы, ишетеп кабул итү, артикуляция аппаратын устеру һ.б. шундый компонентларны үз эченә ала.

*Бәйләнешле сөйләм үстерү* сөйләмнең ике формасын - диалогик һәм монологик сөйләм үстерүне күздә тота. Диалогик сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирү, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе - иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим курсәткеч булып тора.

*Балаларны матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таньштыру* – сөйләм үсешенен әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру түбәндәге бурычларны чишкәндә тормышка ашырыла.

1. Деньяны бербөтен итеп кабул итүне, күзаллауларны формалаштыру.
2. Әдәби сөйләмне үстерү.
3. Эстетик зәвыкны,әдәби әсәрне кабул итүне үстерү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе булып, бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә унай йогынты

ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюлар, уеннар киң кулланыла.

Балаларның игьтибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигьри әсәрләргә зур игьтибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда балалар эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар: "яфраклар, кар бөртекләре кебек очалар","кер юалар, чайкыйлар, сыгалар , "кояшны сәламлиләр ,"кояш нурлары ясылар һ.б.

Матур әдәбият, халык ижаты, күрстмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларнын, җәнлекләрнең образларын имитациялзү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдү, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы, күләмле итеп язылды. Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә ижади якын килү мемкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә курсәтелә. Җәя эчендә күрсәтелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, суз, ижек, фраза кебек сөйлом элементы кабатлауны курсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белан бергә, күмәк, индивидуаль.

## 2.Тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеге планнары

2.1.Беренче кече яштәге балалар (2-3 яшь)

Танып белү өлкәсе

| Үткәрү вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Безнең балалар бакчасы | Чишенү бүлмәсен карау | 1) балаларны чишенү бүлмәсе, андагы җиһазлар белән таныштыру, бүлмәләрдә (төркемдәге) ориентлашу тәҗрибәсе туплау;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен ,игътибарын,диалогта катнашу теләген үстерү;<br>3)җиһазларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Йомшаккай бездә кунакта | 1) балаларның уенчыклар турында гыбелемнәрен киңәйтү, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын формалаштыру, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру;<br>2) тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләген үстерү;<br>3)сөйләм этикетының гади формаларын (исәнлә- шү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, уен- чыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Йомшаккай тагын бездә кунакта | 1) уенчыкларны карарга һәм аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтү; уенчыкларның исемен, өлешләрен әйтү, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертү;<br>2) тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) сөйләм этикетыныңгади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү ,кызыклы уенчыклар белән уйнаудан тәм табу, шатлык хисләре тәрбияләү. |
| | | Тупны коткарабыз (рәсем буенча) | 1) рәсемнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерү;<br>3)башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | | Юыну бүлмәсен карау | 1) балаларны юыну бүлмәсендәге предметлар (сабын, сөлге, кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән таныштыру, функциональ билгеләнешләре турындагы күзаллауларын ачыклау;<br>2) сүзләрне төрле грамматик формаларда (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.) куллану осталыгына ирешү, балаларның сөйләм активлыгын, инициативасын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү ,саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү омтылышы тәрбияләү. |
| 11.09-30.09. | Көз | Көзге табигать | 1) балаларның көз (табигатьтәге үзгәрешләр,кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади күзаллауларын формалаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү;<br>3) көзге табигатькә соклан ухисләре тәрбияләү. |
| | | Җиләк-җимешләр | 1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк- җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтү ,җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларның билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын үстерү;<br>2) балаларның игътибарын, үзләштерү, кабул итү һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белергә гадәтләндерү,әйләнә-тирә табигать |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | объектларына кызыксыну тәрбияләү. |
| | | «Безнең Алсу» сериясеннән рәсем карау | 1) рәсемдәге предметларны таный һәм исемен әйтә белергә, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләренә ирешү;<br>3) рәсемне кызыксынып карау теләге тәрбияләү. |
| | | Яшелчәләр: помидор,кыяр, кишер белән таныштыру | 1) балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл,йомшак, шома, тәмле, сусыл, хуш исле, шар формасындагы помидор; яшел,каты,шома,кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер)белән таныштыру;<br>2) балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу)кулланырга гадәтләндерү, зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Рәсемдәге кошларны карау | 1) балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдыру, кошларга карата кызыксыну уяту;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген һәм сүз байлыгын үстерү;<br>3) кошларга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| | | Көз (йомгаклау чарасы) | 1) балаларның көз турындагы белемнәрен (яфраклар саргая, сары яфраклар, яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы киемнәрен kияләр) ныгыту, тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда, буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төшерергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту;<br>2) балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, рәсем ясарга кызыксындыру;<br>3)көзгет абигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| 1.10—15.10 | Мин—дөньяның бер кешесе | Минем исемем бар | 1) баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү;<br>2) тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайбер фразаларны (Минем исемем—Алсу) кабатларга күнектерү, хәтерне, игътибарны үстерү;<br>3) балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Бу—мин | 1) организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыклау һәм ныгыту;<br>2) гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>3)үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы булу, культура-гигиена күнекмәләрен үтәүтеләге тудыру. |
| 16.10—4.11 | Минем әйләнә-тирәм | Яраткан уен бүлмәбез | 1) балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам иттерү, уен (төркем) бүлмәсе, андагы махсус почмаклар белән таныштыру, «һәр әйбернең үз урыны» дигән төшенчәне аңлату һәм ныгыту;<br>2) сүзләрне һәм кыска фразаларны ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын үстерү;<br>3) җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык тәрбияләү. |
| | | КамАЗ машинасы | 1) балаларны КамАЗ машинасын һәм аның өлешләрен танырга, исемен әйтергә өйрәтү; уенның сүзләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, эмоциональлеген үстерү;<br>3) балаларда йөк транспортына, өлкәннәрхезмә- тенә карата кызыксыну уяту. |
| | | «Безнең урам» | 1) балаларны урам,андагы объектлар,күренешләр белән таныштыру, аларга карата кызыксыну уяту;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын,сүз байлыгын үстерү;<br>3) урамга соклану хисе тәрбияләү. |
| | Яңа ел бәйрәме | Электр лампасы белән таныштыру | 1) электр турында балаларга гади төшенчә бирү (электртогы электрчыбыкларында«яши»;утны яндыру өчен, өзгечкә (выключательгә) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток килә); *электр, ток, чыбык, өзгеч*(*выключатель*)сүзләре хисабына сүзлекне үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итү сәләтен үстерү, ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерү;<br>3) сакчыллык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Гирлянда | 1) балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү, электр тогы турындагы күзаллауларын ныгыту, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, шатлык хисләрен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү;<br>3) күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү. |
| | | Яшел чыршы | 1) балалар белән бергәләп чыршыны карау, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3)матурлыкны күрә һәм аңа соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Чыршы бизибез | 1) балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итү;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүзлеген активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын,игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Без музыка залында | 1) чыршы бәйрәменә әзерләнү: балаларны музыка залының бизәлеше чыршы уенчыклары,аларның материалы, төсе, формасы белән таныштыру; *чыршы уенчыклары, йомры, пыяла, шома, ялтырый* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, күзәтүчәнлеген, игътибарын, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3)балаларда эстетик хисләр тәрбияләү. |
| 01.01.-31.01. | Кыш | Ап-ак кар ява | 1) балаларны кар һәм аның үзлекләре (актөстә, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштыру, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның сүз байлыгын, игътибарын,күзә-түчәнлеген үстерү;<br>3) кышкы табигатькә соклану хисе ,бергәләп уйнау теләге тәрбияләү. |
| | | Алсу урамга җыена | 1) балаларның кышкы киемнәр турындагы белем- нәренә төгәллек кертү,урамга чыкканда киен үэзлеклелеген һәм киемнәрне истә калдырырга өйрәтү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүз байлыгын үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3)башкаларга ярдәм итү теләге булдыру,киемнәргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Ләйлә суыктан курыкмый (рәсем буенча)<br>О,И Соловьва картинасы буенча) | 1) рәсемне карарга, рәсемдәге предметларны танырга, исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү; предметларны, эшхәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру, рәсемэчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә күнектерү;<br>2) кабул итү сәләтен, игътибарны, хәтерне үстерү;<br>3) сюжетлы рәсемнәр карарга теләк уяту. |
| | | Күгәрченнәр, чыпчыклар—безнең нәни кошчыклар | 1) мәйданчыктагы җимлеккә килгән кошларны , күзәтү,исемнәрен әйтү;*гөр-гөр,чырык-чырык,кар- кар*авазиямтемнәренчыкәйтергәкүнектерү;, *томшык,сикерә,гөрлиләр,җим,чүплиләр,чырыл дый,җитез,өлгер*сүзләрехисабынасүзлекне баету;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген,сорауларга җавап бирү осталыгынү стерү;<br>*3)* кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| 1.02-8.03 | Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр | Безнең әтиләр (сюжетлы рәсемнәр карау) | 1) балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәр карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү, эшгамәлләрне белдерә торган сүз- ләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүзбайлыгын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |
| | | Безнең апа (тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү) | 1)тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш хәрәкәтләрне әйтергә өйрәтү (савыт-сабаюа,ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.),сүзлекне активлаштыру, яңа сүзләр белән баету,уенчыкларны күләмнәре (зур, кечкенә) буенча классификацияләргә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү, катлаулы булмаган биремнәрне үтәү осталыгына ирешү;<br>3) әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну һәмтыңлаучанлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | «Алсу бәйрәмгә җыена» дидактик уены | 1) өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы белән таныштыруны дәвам итү, сүзлекне активлаштыру: *ефәк, ак чәчәкле* кебек яңа сүзләр кертү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сорауларны ишетү, аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) курчаклар белән уйнарга теләк уяту, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Безнеңәнил әр (сюжетлы рәсемнәрка рау) | 1) балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү;<br>3)төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү. |
| 9.03—20.03 | Халык иҗаты | Матрёшкалар | 1) балаларны халык иҗат иткән уенчыклар (матрёшкалар) белән таныштыруны дәвам итү, ма- трёшканы ачарга һәм дөрес итеп җыярга өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру, балаларны үзләренә әйтелгән (мөрәҗәгать ителгән) сүзләрне тыңларга күнектерү;<br>2) игътибарны, хәтерне ,сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) халык иҗатына кызыксыну, уенчыкларга(матрёшкага) карата сакчыллык тәрбияләү. |
| | | Матрёшкалар | 1) уенчыкның (матрёшканың) исемен дөрес әйтергә, төсендә һәм зурлыгында булган аермалыкларны күрә белергә күнектерү; *зур, кечкенә, сарафан, яулык*сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3)балаларда халык уенчыкларына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| 1.04—30.04 | Яз | Яз,язкилә... | 1) балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта ,сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2)балаларның күзәтүчәнлеген,игътибарын үстерү;<br>3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Җәнлекләр урманда шиләр | 1) җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту, җәнлекләрне таный һәм исемнәрен атый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү;<br>3) җәнлекләр белән кызыксындыру. |
| | | Сыерчыклар, карлыгачлар килде (рәсемнәр карау) | 1) балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтү; балаларның сүз байлыгын арттыру,сүзлеккә *сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач* сүзләрен кертү;<br>2) игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар һәм табигать белән кызыксынуларына ирешү, кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Песиле тал бөреләрен карау | 1) балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштыру, табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү, сүз байлыгын киңәйтү һәм *песиле тал, ботак, бөре, йомшак*, *хуш исле* сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен,игътибарын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) табигать белән кызыксыну, табигать матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү. |
| 1.05—31.05 | Җәй | Тузганак чәчәген карау | 1) балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү, тузганак чәчәген күрсәтү, анытанырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү; *тузганак, чәчәк, сабак* сүзләрен сөйләмдә активлаштыру;<br>2) балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Йорт хайваннары | 1) балаларның йорт хайваннары (сыер, ат,песи,эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү;<br>2) сүзлекне баету, тәрбиячнең сорауларын аҗавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү телә-ген үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Балалар табык һәм чебиләр ашата (рәсем буенча) | 1) балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләрен тыңларга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) сөйләмне*томшык, тавык, чебиләр, табак* сүзләре хисабына баету, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү;<br>3) йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| | | Ком һәм аның үзлекләре | 1) балаларны комны тикшерергә (комны учка алырга,йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү;<br>2) *коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү* сүз- ләре хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарын, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) ком белән уйнарга кызыксындыру. |

Сөйләм үстерү өлкәсн

| Үткәрү вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Безнең балалар бакчасы | Кем нәрсә эшли? | 1) балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү, рәсемнәр карарга, анда сурәтләнгән предметлар- ны һәм аларның сыйфатларын әйтергә, рәсемдә сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3)уенчыкларга карата сакчы лмөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | | Предметлар ның төсләрен тану һәм әйтү. «Паровоз» дидактик күнегүе | 1) төсләрне белдерә торган сыйфатлар (кызыл, яшел, сары) хисабына балаларның сөйләмен баету, [ү] авазыныңдөрес әйтелешенә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерү;<br>3) эшчәнлеккә карата кызыксыну, бергәләп уйнау, шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Уенчыклар бездә кунакта | 1) төсне, зурлыкны, эшгамәлне белдерә торган сүзләр (*зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт*) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгын формалаштыру;<br>2) исеме, төсе, размеры буенча балаларның предметны табу осталыгын, сенсор тою сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Пирамидалар | 1) балаларны предметларның зурлыгын, төсен билгеләргә өйрәтү, төсне (*кызыл, яшел, сары, зәңгәр*), зурлыкны (*зур—кечкенә, зуррак—кечкенәрәк, иң зурысы—иңкечкенәсе*) белдерә торгансүзләр ярдә мендә сүз байлыгын арттыру, аваз ияртемнәрен ачык әйтүдә күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итүне, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>түземлелек, дидактик уеннар белән кызыксыну тәрбияләү. |
| 11.09-30.09. | Көз | Яшелчәләр | 1) яшелчәләрне белдерә торганисемнәр(бәрәңге, помидор, суган, кишер)һәм аларның үзлекләрен белдерүче сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету,яшелчәләрне танырга өйрәтү,сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>2) балаларның сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) яшелчәләр,аларныңфайдасытурындамәгълү- мат бирү. |
| | | «Җил исә» уен күнегүе. «Кем нәрсә ашый?» дидактик күнегүе | 1) балаларның төсләр турындагы күзаллавын ныгыту, җәнлекләрнең нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачыклау; *ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый* фигыльләрен сөйләмдә активлаштыру, авыз аша һаваны әкрен, салмак кына чыгарырга өйрәтү;<br>2) игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3) җәнлекләргә, кошларга карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Урманда | 1) балаларның олылар белән аралашу теләген хуплау, исем һәм сыйфатларны кулланырга өйрәтү: *йомшак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре;* кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне активлаштыру: *төлке бара, куянсикерә, аюалпан-тилпәнй өри* һ .б.;<br>2) ишетү игътибарын,координацияләрне, ритм хисен үстерү;<br>3)кыргый хайваннарга карата кызыксыну тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.10—15.10 | Мин—дөньяның бер кешесе | Алсубүлмәсе | 1) балаларны өй җиһазларын таный һәм атый белергә өйрәтү; *өстәл, урындык, карават, шкаф, көзге* кебек исемнәр хисабына сүзлекне активлаштыру,сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>2) балаларныңуңай эмоцияләрен, кызыксынучанлыгын үстерү;<br>3) бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| | | «Бу өйдә кем яши?»дидактик уены | 1) төркемгә йөрүче балаларның исемнәрен истә калдырырга ярдәм итү, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда куллана белергә өйрәтү, сорауны белдерә торган сүзләрне кулланырга күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен, диалогиксөйләмне үстерү;<br>берберенә карата игътибарлылы ктәрбияләү. |
| 16.10—4.11 | Минем әйләнә-тирәм | Алсубездә кунакта | 1) балаларга һөнәрләр (табиб, полици яхезмәткәре) турында мәгълүмат бирү, грамматик яктан җөмләләрне аңларга һәм аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, кабулитү сәләтен үстерү;<br>3) һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Әминәнең туган көненә килегез | 1) [к] һәм [к] авазларының сүзләрдә һәмсөйләмдә дөрес әйтелешен ныгыту, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтү, савыт-сабаларны белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне киңәйтү һәм активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрне аңлый һәм куллана белүләренә ирешү, җөмләләр белән җавап бирергә күнектерүне дәвам итү;<br>2) инициативалы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерү, башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудыру;<br>3) үзарааралашуга омтылыш тәрбияләү. |
| | | Минем гаиләм | 1) сөйләмдә ягымлысүзләрне(әти—әтием, әни— әнием,әби—әбием,сеңел—сеңлем) кулланырга өйрәтү, [ә]авазының әйтелешен ныгыту, аныачык, тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүгә ирешү, тәр- бияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларныңигътибарын, хәтерен үстерү,зур- лар һәм иптәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү;<br>3)гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү. |
| | Яңа ел бәйрәме | Купшычыршы | 1) сузык һәм тартык авазларны, аваз иярткемнәрен ачык әйтергә, сыйфатларны дөрес кулланырга күнектерү, *түбәндә*сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү осталыгын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| | | Куян Чыршы янында | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (*эчендә, артында, астында, өстә, өстендә*) кулланырга, *кайда? кая?* сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү, тавыш көчен дөрес куллану осталыгын формалаштыру;<br>2) игътибарны үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәүдә күнектерү;<br>3) нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Песи беләнкәҗә чыршы янында | 1) балаларнытәрбиячесорауларынаҗавапбирергә өйрәтүне дәвам итү,сөйләмдә фигыльләр һәм сый- фатлар куллануны активлаштыру, [ж] авазын иҗекләрдә, сүзләрдә, җөмләләрдә дөрес һәм ачык әйтүләренәирешү;авазияртемнәренкабатлаганда, тавыш көчен җайлый белүдә күнектерү;<br>2) игътибарны,кабулитүсәләтен,тәрбиячекүрсәт- мәләрен үтәү осталыгын үстерү;<br>хайваннаргакараташәфкатьлелектәрбияләү. |
| | | «Тылсымлы» таякчык | 1) балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, төсне белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, ишетү осталыгын үстерү;<br>3) бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| 01.01.-31.01. | Кыш | Кошлар | 1) балаларны аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтергә, алардан фигыльләр (*гөр-гөр—гөрли, чырык-чырык—чыркылдый, кар-кар—каркылдый*) ясарга өйрәтү, гомумиләштерүче сүзләрне (*тавык, әтәч,каз—йорткошлары*)куллanудакүнектерү; кош исемнәрен, гәүдә өлешләрен, хәрәкәтне белдерүче сүзләр хисабына сүзбайлыгын активлаштыру, балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмен үстерү;<br>3) кошларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Юлны чистартабыз | 1) балаларның кыш һәм кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнә- рен формалаштыру, көрәк белән эшләргәөйрәтү, ишегалдын җыештыручы хезмәте белән таныш- тыру, балаларның сүзлеген активлаштыру, аерым сүзтезмәләрне (*зуркөрәк, кечкенәкөрәк, ак кар, күп* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | *кар, әз кар*) ачык итеп әйтүдә күнектерү;<br>2) хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәтләрен имитацияләү осталыгын үстерү;<br>зурларгаярдәм итү һәм гади хезмә тхәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләү. |
| 1.02-8.03 | Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр | «Шундый ук предметны тап» дидактик уены | 1) үз фикерләрен, грамматик яктан дөрес итеп, ике-өч сүздән торган гади җөмләләр белән белде- рергә өйрәтү, гомумиләштерү күнекмәсе булдыру, предметларны чынбарлыкта һәм рәсемдә танырга өйрәтү, предметларның билгеләнешен ачыклау, предмет исемнәрен атау хисабына (*сабын, теш щёткасы, теш пастасы, сөлге*) һәм сөйләмдә кулланылган фигыльләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру һәм баету;<br>2) тәрбияче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгына ирешү, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| | | Машина һәм самолёт | 1) балаларны уенчыкларныңөлешләрен, төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтү; исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләрен формалаштыруны дәвамитү, [у] сузык авазын әйтү- дә күнектерү; *очучы, очып китү, очып төшү, йөк машинасы, самолёт* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру, уенчыклар (машина,самолёт)белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның *нинди? кайда? нәрсә ташый?* сорауларына гади җөмләләр белән җавап бирү оста- лыгына ирешү, игътибарынү стерү;<br>3)шофёр,очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Мәрьямне табыйк | 1)балаларны *кайда? кая?* сорауларына җавап бирергә, сөйләмдә *өстенә, артына, астына* сүзләрен кулланырга өйрәтү;<br>2)балаларның игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3)уенга кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Кына гөле | 1)балаларны бүлмә гөле—кына һәм аның өлешләре белән таныштыру; *сабак, яфрак, чәчәк* сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштыру;<br>2)балаларның зурлар белән аралашуын, аларны аңлауларын, күзәтүчәнлекләрен, игътибарларын үстерү;<br>3)бүлмә гөлләренә карата кызыксынучанлык, аларны карау теләге тәрбияләү. |
| 9.03—20.03 | Халык иҗаты | Бармак уены белән таныштыру. «Йорт | 1) халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны куллануда күнектерү, йорт хайваннарының исемнәрен ныгыту; *мөгри, кычкыра, мияулый, өрә* фигыльләре хисабына балаларның сүзлегенактивлаштыру; [м], [у] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хайваннары» уен күнегүе | 2) хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнекмәләрен үстерү;<br>3) халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | «Чуартав ык» экиятен уку | 1) балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү, әкиятне тыңлау теләге тудыру; *чуар, күкәй, алтын, гади, тычкан* кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету;<br>2) тәрбияче башлаган җөмләне дәвам итү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| 1.04—30.04 | Яз | Бүлмә гөлләре (фикус, яран) | 1) балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә тор-ган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) гөлләр белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) өлкәннәргә гөлләрне карарга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | | Йөк машинас ы | 1) машина, аның өлешләре турында балаларның белемнәрен арттыру, ком һәм аның үзлекләре белән таныштыру; машинаның төрен, өлешләрен, комның үзлекләрен белдерә торган исем нәр,сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштыру; [в], [п] авазларының дөрес әйтелүдә күнектерү;<br>2)кызыксынучанлыкны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) тәрбияче һәм яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләү. |
| | | Язгы урманда | 1) *кайда? нинди?* сорауларына җавап бирергә өйрәтү; *өстә, агач төбендә* сүзләрен куллану хисабына сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; аваз иялтемнәрен ачык, төгәл әйтүдә күнектерү, [ш] авазының әйтелешен ныгыту, ел фасылларына бәйле табигатьтәге үзгәрешләр турындагы белемнәрне формалаштыруны дәвам итү;<br>2)балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3)табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Бозау, бәрән, колын,кәҗә бәтие, сез кайда? | 1) балаларның йор тхайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; *бозау, бәрән, колын, кәҗәбәтие* сүзләре хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру; тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгы формалаштыру;<br>2) игътибарны, хәтерне үстерү;<br>3)башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| 1.05—31.05 | Җәй | Балалар бакчасы | 1) исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүз байлыгын үстерү; фигыльләрне һәм сыйфатларны исемнәр белән яраклаштыруда күнектерү, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ишегалдында | балаларны бакча ишегалдында үсә торган үсемлекләр исеме белән таныштыруны дәвам итү, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәрне киңәйтү;<br>2) төсләрне, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теле компонентларын үстерү;<br>3) табигать объектларына карата кызыксыну,хезмәткә хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Кызыксыну чан тел | 1) балаларны [т], [д], [к], [к] авазлары кергән аваз ияртемнәрен әйтергә өйрәтү, аваз ияртемнәрен төрле югарылыктагы тавыш (калын,нечкә) белән әйтүдә күнектерү; [т], [д], [к], [к] авазларын сүз- ләрдә, фразаларда әйтүне ныгыту;<br>2) [т],[д],[к],[к]авазларын әйтү хисабына сөйләм үстерү,балаларныңфантазиясен баету;<br>игътибарлылык тәрбияләү. |
| | | Зоопарк | 1) җылы якта яшәүче хайваннар белән таныштыру, сөйләмдә исемнәрне берлек һәм күплек саннарда кулланырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен,игътибарын үстерү;<br>3) җылы як хайваннарына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| | | Рәхмәт,җәй! | 1) балаларны яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне тәме буенча аерырга өйрәтүне дәвам итү; яшелчәләр, җиләк-җимешләр, агачлар турындагы белемнәрне киңәйтү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3)табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. |

Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе

| | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Безнең балалар бакчасы | «Үчтеки,үчтеки» такмагын уку | 1) балаларны фольклор әсәрләре белән кызыксындыру, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү;<br>2) балаларныңкабул итү сәләтен ,хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләү. |
| | | Ә. Бикчәнтәеваның «Туп- туп- | 1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, таныш предметларны таный һәм атый белергә, шигырьнең авыр әйтелешле аерым сүзләрен дөрес әйтергә өйрәтү, төсләрне аеру күнекмәсен ны- гыту; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тубыбыз» шигырен уку | 2) балаларныңкабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | С. Сөләйманова - ның «Ике» шигырен уку | 1) балаларны шигъри әсәр белән кызыксындыру, аның эчтәлеген аңларга өйрәтү, баланың үзе ту- рында күзаллавын формалаштыруны дәвам итү; *кул, аяк, колак, күз* сүзләре хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>З) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| 11.09-30.09. | Көз | Йорт хайваннарын чакыру эндәшләрен уку | 1) эндәшнең эчтәлеген аңлату; текстның эчтәлегеннән чыгып, аваз ияртемнәрен, ымлыкларны дөрес әйтүләренә,тәрбиyченең сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) хайваннарны ярату хисе тәрбияләү. |
| | | Д.Гарифуллинның «Йә, алар кемнәр икән?» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дәвам итү; *бак-бак, мә-мә, кар-кар* ав азияртемнәрен кабатлау; балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итү, сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) кошларга, хайваннарга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | | Б.Рәхмәтнең «Су» шигырен уку | 1) тексткатуры китереп,хәрәкәтләр ясарга өйрәтү, [йу] аваз кушылмасын ачык итеп әйтергә күнектерү; сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү;<br>З) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| 1.10—15.10 | Мин—дөньяның бер кешесе | Г.Тукайның «Гали белән кәҗә»шигырн уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларда «Мин—дөньяның бер кешесе» дигән күзаллау булдыру; *кәҗә, чирәм, сакал* сүзләре хисабына сүзлек байлыгын киңәйтү, хәрәкәтләр өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) балаларда бер-берсенә һәм хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | З.Туфайлова ның «Ул зу-у-у-р үскән» | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү һәм хезмәтнең нәтиҗәсен күрә белергә өйрәтү; *утырткан, сипкән, үскән* кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, диалогик сөйләм күнекмәсе формалаштыру; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | шигырен уку | 2) балаларның эмоциональлеген үстерү;<br>3) гөлләргә карата сакчыл караш, матурлыкка соклану тәрбияләү. |
| | | «Песи-нечкәбил» бишек жырын жырлау | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бишек жыры текстына туры китереп, хәрәкәтләр өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) фольклор әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү. |
| 16.10—4.11 | Минем әйләнә-тирәм | М.Җәлилнең «Маэмай» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бармак театры элементларын өйрәтүне дәвам итү, сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның кабул итү һәм истә калдыру сәләтен үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | | М.Җәлил-нең «Әтәч» шигырен уку | 1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, әдәбиәсәрне тыңлау һәм кабул итү күнекмәләре формалаштыру, йорт кошларын тавышлары буенча танырга һәм исемнәрен атарга өйрәтү, [к] һәм [к] авазларының әйтелешен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын ,кабул итү һәм тыңлау сәләтен үстерү;<br>3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | | Ж.Тәржеманованың «Маэмай» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, аерым сүзләрне һәм зур булмаган фразаларны истә калдырырга өйрәтү;<br>2)балаларның игътибарын үстерү;<br>3) этkә карата миһербанлылы\к тәрбияләү. |
| | Яңа ел бәйрәме | Ә. Бикчәнтәеваның «Беренче адым» шигырен уку | 1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, авыр әйтелешле кайберсүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү күнекмәсен үстерү;<br>3) күмәк эшчәнлек күнекмәсе тәрбияләү. |
| | | «Карга әйтә» эндәшен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларның кошлар турында белемнәрен арттыру һәм ныгыту, кошларның тыш кыкыяфәтенә игътибар итү, сүз байлыгын арттыру, [к] авазының дөрес әйтелешенә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) кошлар белән кызыксыну теләге уяту. |
| 01.01.-31.01. | Кыш | Ә.Ерикәйнең «Беренчекар» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, әсәр аша табигать дөньясына җәлеп итү, кышкы табигать турында мәгълүмат бирү; *йомшак, ап-ак* сыйфатлары хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;<br>2) балаларның катлаулы сорауларга җавапбирү осталыгын, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) табигатькә карата мәхәббәт уяту. |
| | | Ж.Тәрҗе-мановның «Йокы бабай» әкиятен сөйләү | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) сорауларга дөрес җавап бирү омтылышы уяту. |
| | | С. Летованың «Кар бабай» хикәясен уку | 1) күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне (хикәяне) күрсәтмәлелек кулланмыйча тыңлау һәм ка- бул итү, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, балаларның әңгәмә вакытында җиңел һәм иркен аралашуларына ирешү, сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның игътибарын, бергәләп тыңлау күнекмәсен үстерү;<br>3) сүзсәнгате белән кызыксыну тәрбияләү. |
| 1.02-8.03 | Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр | Ш.Маннур-ның «Яра-там» шигы-рен уку | 1)шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, [ә] авазын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2)балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3)әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләү. |
| | | «Кәккүк-чыпчык» уены | 1)[ч], [к] һәм [қ] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;<br>2)Балаларның эмоциональлеген үстерү;<br>3)Фольклор әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. |
| | | Г.Таһировның «Йокла, курчак» шигырен уку | 1)Шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү; [ә], [ү] авазларын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2)Балаларның игътибарын үстерү;<br>3) курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Ә.Кариның | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү, фланелеграфта шигырь |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | «Тавык»шигырен уку | эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр яки уенчыклар күрсәтү; кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйләмен актив- лаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әбиләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү. |
| | | Э. Шәрифул- линаның «Иң матур әни» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвамитү; кайбер фразаларны кабатлатып, балаларныңсөй- ләмен активлаштыру;<br>2) балаларныңигътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әниләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү. |
| 9.03—20.03 | Халык иҗаты | «Йомры икмәк» рус халык әкиятен уку | 1) балаларны «Йомрыикмәк» әкияте белән таныштыру, әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, шар әвәләү күнекмәсен ныгыту, сорауларга җавап бирү осталыгына өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларныңкабул итү сәләтен,игътибарын, активлыгын үстерү;<br>3) әкият белән кызыксындыру. |
| | | «Йомры икмәк» әкиятен кабатлау | 1) әкиятне тәрбияче белән бергә сөйләргәөйрәтү; аерым фразаларны кабатлатып, балаларныңсүз байлыгын активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) әкият геройлары белән кызыксындыру. |
| | | «Терем кә» рус халык әкиятен уку | 1) балаларны яңа әсәр белән таныштыру, әкиятне аңлап тыңларга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) халык иҗатына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | «Теремкәй» әкиятен сәхнәләштерү | 1) әкият белән таныштыруны дәвам итү; балаларны сәхнәләштерү эшчәнлегенә җәлеп итү, уен бары- шында фразаларны дөрес әйтү осталыгына ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, активлыгын үстерү;<br>3) әкиятләр белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. |
| 1.04—30.04 | Яз | Ш.Галиевнең | 1) балаларның шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, язгы табигать турында мәгълүмат бирү; [т] авазын, *тып* аваз ияртемен дөрес әйтергә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | «Яз» шигырен уку | күнектерү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаш- тыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен,игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү;<br>3) язгы табигать күренешләре белән соклану хисе тәрбияләү. |
| | | «Тор-тор, тургай» такмагын уку | 1) такмакның эчтәлеге белән таныштыру, [т] авазын дөрес әйтергә күнектерү, аваз ияртемнәре хи- сабына балаларның сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) фольклор әсәрләре белән кызыксындыруны дәвам итү. |
| | | «Тук ,тук, тукран» эндәшен уку | 1) шигъри текстны тыңлау осталыгы формалаштыру, кошлар белән таныштыруны дәвам итү, аваз ияртемнәрен кабатлау, [т] , [к] һәм [к] авазлары кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) кошларга карата шәфкатьлеле ктәрбияләү. |
| | | «Кояш, чык, чык» эндәшен уку | 1) балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетны истә калдырырга ярдәм итү;<br>2) балаларның тыңлый белү осталыгын, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) күмә кэшчәнлек белән кызыксындыру. |
| | | Р.Батулланың «Нурбәк» әкиятен уку | 1) әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтүне дәвам итү; [а], [у], [ә] сузык авазларындөрес әйтергә күнектерү, уенчыкларда әкият персонажларын танырга һәм атарга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) әкият геройлары белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | | К.Д.Ушин - скийның «Казлар» хикәясен уку | 1) казларны һәм үрдәкләрне аера белергә өйрәтү, хикәяне күрсәтмәлелек кулланмыйча аңлап ка-бул итүләренә ирешү, күплек һәм берлек саннар- дагы исемнәрне аерырга һәм дөрес кулланырга күнектерү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбияченең күрсәтмәләрен үти алу оста- лыгын үстерү;<br>3) йорт кошлары белән кызыксыну тәрбияләү. |
| 1.05—31.05 | Җәй | Ә.Каринының «Чебиләр» шигырен уку | 1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, шигъриәсәрне тыңларга өйрәтү, [ч] авазын дөрес әйтергә күнек- терү;<br>2) балаларның уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) йорт кошларына карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | С.Сөләйма - нованың «Кызылтәч» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне тыңларг аәйрәтү, гади сорауларга җавап бирү теләге уяту, ава зияртемнәрен өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү;<br>3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | | Д.Га ри- фулл лин- ның «Мыраубикә» шигырен уку | 1) шигырь ярдәмендә песи белән таныштыруны дәвам итү, песи турында мәгълүматларны ныгыту һәм киңәйтү; *мыр-мыр, гыр-гыр* аваз ияртемнәрен өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3)песиләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

2.2.Икенче кече яштәге балалар (3-4 яшь)

Танып белү өлкәсе

| Вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | Кояш, чык! | 1)җәй турында күзаллауларга нигез салу, тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү;<br>2)балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен; күз алдына китерә, хыяллана белүләрен; вак моториканы, рәсем ясау күнекмәсен, иҗади сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда табигать белән кызыксыну тәрбияләү |
| | | Йомшаккай әзерләгән сюрприз | 1) агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында агач материалы, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтү;<br>2) предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлек байлыгын, хәтерләрен, игътибарларын үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл караш, уеннан соң уенчыкларны урынына кую |
| | | Манара | 1) балаларны төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге төзү материалы - шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2) предметның төсен, формасын, зурлыгын атый белүләренә ирешү;<br>3) бергә шөгыльләнү теләге уяту; балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| 11.09.-<br>30.09. | Көз | Куян үстергән кишер һәм помидор | 1) балаларга табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмен, сенсорик күнекмәләрен үстерү;<br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү. |
| | | Сары, кызыл яфраклар | 1) балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турында мәгълүмат бирү; көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яфракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү; көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү;<br>3) балаларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү. |
| 01.10.-<br>15.10. | Мин һәм минем гаиләм | Кунак каршылыйбыз | 1) савыт-сабаның аерым предметлары, аларның ку- лланылышы турында белемнәенә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; әңгәмәгә тарту;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү;<br>3) балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, танышу, саубуллашу); өлкәннәргә булышу теләге уяту; савыт- сабага сакчыл караш тәрбияләү. |
| 16.10.-<br>04.11. | Минем йортым, минем шәһәрем | Мин – «КамАЗ» оныгы. | 1) балаларны туган шәһәр, аның исеме (Яр Чаллы), шәһәрдә ясала торган «КамАЗ» машинасы белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирү;<br>2) аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү;<br>«КамАЗ» машиналары белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) туган шәһәр, «КамАЗ» эшчеләре, аларның хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15.11.-<br>31.12. | Яңа<br>ел<br>бәйрәме | Тылсымлы шкатулка.<br>. | 1) балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту, чыршы уенчыкларының төрләре белән таныштыру, аларны күзәтергә теләк тәрбияләү;<br>2) балаларны чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләргә өйрәтү, диалогик сөйләмнәрен үстерү, сорауларга җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү; аңга алуларын үстерү; берничә сенсорик билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә берләштерергә өйрәтә башлау;<br>3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү; балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру. |
| | | Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз | 1) балаларның кышкы та- бигатьнең характерлы үзенчәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, тикшеренүләр барышында суның үзлекләре турында мәгълүмат бирү; авазларның артикуляциясен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, танып белү активлыкларын формалаштыру;<br>3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру; җәнлекләргә карата кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. |
| 01.01.-<br>31.01. | Кыш | «Чанада шуабыз» рәсемен карау | 1) балаларны рәсемне карарга, аның эчтәлеген аңларга, эч- тәлеге буенча сорауларга җа- вап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) диалогик сөйләмнәрен; күзәтүчәнлекләрен, күрсәтмә образлы фикерләүләрен үстерү;<br>3) кышның матурлыгын күрә белергә өйрәтү. |
| | | Җимлек янында.<br>. | 1) кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру; аларны тышкы кыяфәтләре буенча танырга өйрәтүне дәвам итү; пумаланың очы белән ярма бөртекләре ясауны ныгыту;<br>2) аваз ияртемнәрен әйтүдә күнектерү; сүзлек запасын баету, күзәтүчәнлекләрен, игътибарлылыкларын үстерү;<br>3) кошларга карата сак караш, алар турында кайгыртучанлык, кышын аларны тукландыру теләге тәрбияләү. |
| 01.02.-<br>23.02.. | Ватанны саклаучыл ар көне | Ватанны саклаучылар көне | 1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, монологик сөйләмнәрен үс- терү;<br>3) балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле, кыю булырга омтылыш тәр- бияләү. |
| 24.02.-<br>08.03.. | Сигезенче Март | Минем әнием | 1) әниләр турында әңгәмәдә катнашырга, әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү; әзер формалардан бизәк төзеп, кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) балаларда пөхтәлек, әниләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 09.03.-<br>31.03. | Халык җәүһәрлә ре | Тере һәм уенчык кошларны карау | 1) тере һәм уенчык кошны чагыштырып, уенчык кош– дымка уенчыгы белән таныштыру, уенчык кошның инди материалдан ясалган булуын ачыклау; төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәнүне дәвам итү;<br>3) кошлар белән кызыксыну, аларга карата сак караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| 01.04.-<br>20.04. | Яз | Урамда яз | 1) балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) ачыклау бары- шында сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү;<br>3) язгы күренешләр белән кызыксынуларын үстерү, табигатьтә барган үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту. |
| 02.05.-<br>31.05. | Җәй | «Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре» рәсемен карау | 1) балаларны тәрбияче яр- дәме белән рәсемнең эч- тәлеген аңларга, аның ту- рында сөйләргә өйрәтү, йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөй- ләмен, дуслык турында күзаллауларын үстерү;<br>3) тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белергә өйрәтү; хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Тузганак чәчәген карау | 1) балаларны туган як үсемлекләре (тузганак) белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) үсемлекне карау барышында әңгәмәгә тарту; хәтерне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3) үсемлекләр белән кызыксыну, эстетик хисләр тәр- бияләү. |

Сөйләм үстерү өлкәсе

| Вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-<br>10.09. | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | «Ә» авазы | 1) «ә» сузык авазын дөрес итеп, кыска һәм озын итеп әйтергә күнектерү. «Ә» авазын аерым, сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүненыгыту;<br>2) сорауларга җавап бирергәтеләк уяту;<br>3) сюжетны чагылдыра торган еннарда катнашу теләге тәр- бияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11.09.-30.09. | Көз | Бакчада алмалар өлгерде | 1) балаларның көз, табигать-тәге көзге үзгәрешләр, җиләк-җимешләр (алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләркергән җөмләләр төзергә өйрә- түне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аңгаалуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү;<br>3) күмәк эшләүгә тарту, сора-уларга җавап бирү теләге тәр-бияләү. |
| | | Алтын көз | 1) тиңдәш кисәкләрдән торган җөмләләр төзергә, аерым предметлардан төркем төзергә, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтүне дәвам итү; предметларның саны буенча бәйләнеш урнаштырганда, «бер», «күп», «аз», «берәү дә юк» сүз-ләрен куллана, сүзләрдә [с], [з],[ф], [к] тартыкларын ачык итепәйтә белүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, зиһенгә алуларын үстерү; тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; табигатьнең матурлыгын аңларга өйрәтү;<br>3) табигатькә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| 01.10.-15.10. | Мин һәм минем гаиләм | Безнең гаилә | 1) балаларның гаилә һәм гаилә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; исемнәрне сан, тартым белән төрләндерүгә (әни-әниләр, әни-әнием) күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;<br>3) олылар белән ирекле аралашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлылык, кайгыртучанлы к тәрбияләү. |
| 16.10.-04.11. | Минем йортым, минем шәһәрем | Уенчык песи баласы турында хикәяләү | 1) балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уен- чыкны карауга балаларны җәлепитү; уенчыкны сорауларга җавапбирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, аңгаалуларын, күзәтүчәнлеген, сүзлек байлыгын үстерү;<br>3) тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту; йорт хайваннарына карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. |
| | | Алсуның яңа өе. | 1) балаларны йорт җиһаз-лары белән таныштыру, билгеләнешләре буенча гомумиләштерергә өйрәтү; бирелгән сорауны аңлау һәмҗавап бирүләренә ирешү;<br>2) җиһаз предметларының атамасын һәм билгеләнешен, аларның нинди материалдан эшләнгәнен ачыклауларына ирешү; *артында, янында, өстендә* кебек сүзләр хисабынасүзлек байлыгын үстерү;<br>3) йорт җиһазларына каратасакчыл караш тәрбияләү. |
| 15.11.-31.12. | Яңа ел бәйрәме | Төлке бездә кунакта | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне(эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, «кайда?, «кая?» сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) игътибарны, тәрбиясенең күрсәтмәләре буенча эшләү күнекмәләрен үстерү;<br>3) җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 01.01.-<br>31.01. | Кыш | Алсуны урамга киендерәбез. (Кышкы киемнәрне карау) | 1) кышкы киемнең билгеләнешен, төсен, аерым детальләрен, материалын атап,аны сурәтләргә; исемне сыйфатбелән бәйләп, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел, зәңгәр сүзләре хисабына сүзлекләрен<br>активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүләрен, игътибарларын, күрү хәтерләрен үстерү;<br>3) киемнәргә карата сакчылкараш тәрбияләү. |
| | | Кар ява | 1) балаларның кыш турындакүзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сөйләмдә сыйфатларны дөрескуллана белүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын,диалогик сөйләмен, рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентлашуларын, сөйләм сулышынүстерү;<br>3)башкаларга ярдәм итү теләгетәрбияләү. |
| 01.02.-<br>23.02.. | Ватанны саклаучылар көне | Очучылар | 1) балаларны самолетның өлешләрен, зурлыгын, формасын билгеләргә һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сый- фатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүгә күнектерүне дәвам итү; *очучы, очып китү, очып төшү, аска, өскә, уңга, сулга, самолет* сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирүләренә ирешү, игътибарларын үстерү;<br>3) очучы һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр тәрбияләү. |
| 24.02.-<br>08.03.. | Сигезенче Март | Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа! | 1) балаларның әниләр бәйрәме турындагы белемнәрен киңәйтү,[ә] авазын ачык итеп әйтүләрен камилләштерү; әңгәмәдә катнашуга тарту;<br>2) балаларның игътибарын, аңгаалуларын, хәтерен, диалогик сөйләм формасын үстерү;<br>3) балаларда әниләргә мәхәббәтһәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| 09.03.-<br>31.03. | Халык җәүһәрләре | «Теремкәй» рус халык әкиятен сөйләү | 1) балаларны әкиятне игътибарбелән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү;<br>2) *Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Сорыколак, аю- Камытаяк* сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету, активлаштыру; игътибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү;<br>3) халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. |
| 01.04.-<br>20.04. | Яз | Бозау, колын, бәрән турында сөйлибез | 1) язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү; тәрбиячебелән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә, капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне (*зур – кечкенә, калын – нечкә*) таба һәм куллана белергә өйрәтүне дәвам итү; балаларның аваз иялтемнәрен әйтә белүләрен ныгыту;<br>2) балаларның аңга алуларын,монологик сөйләмен үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү. |
| 02.05.-31.05. | Җәй | Автобуста сәяхәт | 1) балаларның аваз иярттемнәренәйтә белүләренә ирешү, йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту, йорт хайваннары, кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) кошларның, хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр, иркәләп, яратып әйтелә торган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;<br>3) тере һәм тере булмаган табигать белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Мин җәйне яратам | 1) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдәкулланууларын активлаштыру, «бер», «күп» төшенчәләренныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, уңай хис-кичерешләрен, аңга алуларын үстерү;<br>3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |

Матур әдәбият белән танышу

| Вакыты | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| 20.08.-10.09. | Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы! | З. Гомәрованың «Ул шуңа кечкенә» дигән шигырен уку | 1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтүне дәвам итү; аерым сүз-ләрне, фразаларны тәрбияче артыннан дөреситеп кабатлауларына ирешү; сүзлекләрен активлаштыру;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерләрен, хәрәкәт активлыкларын үстерү;<br>3) әсәргә карата кызыксыну уяту, сәламәт яшәү теләге тәрбияләү. |
| | | Э.Мөэминованың «Үз телендә сөйләшә» шигырен уку | 1) балаларны Э. Мөэминованың «Үз телендә сөйләшә» дигән шигыре белән таныштыру; аерым сүзләрне тәрбияче артыннан кабатлап, сөйләмдә активлаштыру;<br>2) аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;<br>3) туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге |
| | | Ә. Бикчәнтәеваның «Туп» шигырен яттан өйрәнү | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; сорауларга җавап бирүгә күнектерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, хәтерен, интонацияле сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда кечкенәләр турында кайгыртучанлык хисе тәрбияләү; бергә шөгыльләнергә теләк уяту. |
| 11.09.- | Көз | «Аю белән Бабай» | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; үсемлекләр турындагы белемнәрен киңәйтү; сүзлекләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30.09. | | әкиятен уку. | баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен, кулның вак моторикасын үстерү;<br>3) халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү. |
| | | Ә. Ерикәйнең «Көз» шигырен яттан өйрәнү | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга, аны истә калдырырга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү; шигырьдәге килде, *саргайды, шиңде, сибелде* фигыльләре хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарларын үстерү;<br>3) көзге матурлыкка соклану хисе, күзәтүчәнлек тәрбияләү. |
| | | М. Фәйзуллинаның «Көзге яңгыр» шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, уен барышында чикләнгән мәйданда йөгерергә күнектерү;<br>2) аңга алуларын, игътибарларын үстерү; тәрбияче сигналы буенча хәрәкәт итәргә өйрәтү;<br>3) шигъри әсәр белән кызыксыну, уен ярдәмендә тыңлаучанлык тәрбияләү. |
| 01.10.-15.10. | Мин һәм минем гаиләм | Ә.Бикчәнтәева аның «Бәтиләр» шигырен уку | 1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; йортхайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү һәм тирәнәйтү; сорауларга тулы җаваплар бирергә, аваз ияртемнәрен дөрес кабатларга өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, сүзлек байлыгын, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык хисе тудыру. |
| | | Ш. Маннурның «Яратам» шигырен яттан өйрәнү. | 1) шигырнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; сүзлекне баету һәм активлыштыру; гаилә сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү;<br>2) шигъри әсәрне яттан сөйләргә теләк уяту; аңга алуларын, хәтерне, игъти-барны үстерү;<br>3) гаиләгә карата хөрмәт,туганлык хисләре тәрбияләү. |
| | | «Кем нәрсә ярата?» дигән татар халык әкиятен сөйләү. | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; балаларның йорт кошлары һәм хайваннары турындагы күзаллауларына төгәллек кертү; аваз ияртемнәрен ачык һәм дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, образлы фикерләүләрен, ишетү сәләтен үстерү;<br>3) кошларга, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16.10.-04.11. | Минем йортым, минем шәһәрем | «Әлли-бәлли итәргә ...» бишек жырын уку. | 1) бишек жырының эчтәлеген, тәрбияче сөйләмен аңлауларына ирешү; сөйләмдә *тирбәтергә* фигылен куллана белергә өйрәтү;<br>2) аңга алуларын, игътибарны, конкрет- образлы фикерләүләрен үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади кагыйдәсен (тәмле йокы теләү) тормышта куллану теләге уяту; бишек жырлары белән кызыксыну, аларны уен вакытларында жырларга омтылыш тәрбияләү. |
| | | Н. Каштанның «Безнең сыер» шигырен уку. | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; кайбер сүзләрне (мөгери, китер, йөгер) үзләштерүләренә ирешү, [у] авазы кергән аваз ияртемнәрен әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның игъти-барын, аңга алуларын үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык,мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү. |
| | | Ж. Тәрҗемановның «Үзен бик чиста йөртә» шигырен уку. | 1) балаларның яңа шигырьне эчтәлеген аңлапкабул итүләренә ирешү, сорауларга төгәл итеп җавап бирергә күнектерү;<br>2) аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен, хәрәкәтләре төгәллегенен үстерү;<br>3) балаларда пөхтә һәм чиста йөрү теләге тәрбияләү. |
| | | «Олыга – утын ярырга» бармак уены | 1) фольклор әсәрләренә карата кызыксыну уяту; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешү;<br>2) балаларда уңай эмоциональ халәт булдыру;<br>3) хезмәткә уңай караштәр бияләү. |
| 15.11.-31.12. | Яңа ел бәйрәме | Б.Рәхмәтнең «Кыш бабай» шигырен яттан өйрәнү. | 1) эчтәлеген аңлауларына,тәрбияче сорауларын аңлап җавап бирүләренә ирешү; шигырьне яттан сөйләүгә омтылышларын хуплау, сорауларга текст сүзләре белән җавап бирүгә күнектерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сүзлеген, игътибарын, хәрәкәтләр төгәллеген үстерү;<br>3) балаларда Кыш бабайга, Яңа ел бәйрәменәкарата уңай хисләр тәрбияләү. |
| | | И.Шәйм өхәм-мәтовның | 1) балаларны хикәя беләнтаныштыру, мактанчык сүзен сөйләмдә активлаштыру, тәрбияче биргән сорауларга аңлап җавап бирергә күнектерү ;әйләнә-тирә турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игъти- барын, сүзлек байлыгын үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | «Мактанчык бака»әсәрен уку. | 4) балаларда тыйнаклык; бергә шөгыльләнү теләге әрбияләү. |
| | | Р. Вәлиеваның «Сүз тыңлаучан булыгыз» шигыренуку. | 1) балаларны Р.Вәлиеваның шигыре белән таныштыру, сорауларга төгәл җавап бирүләренә ирешү, *җиһаз* сү-зен актив сүзлеккә кертү. Җиһаз атамаларын таный һәм атый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын,хәтерен, диалогик сөйләмен үстерү;<br>3) тыйнаклык, тыңлаучанлык тәрбияләү, кунакта үз-үзеңне тотабелү кагыйдәләрен үзләштерә башлау. |
| 01.01.-31.01. | Кыш | Һ.Такташның «Ләйлә» шигыренуку | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына, сорауларга дөрес җавап бирүләренә ирешү; тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга теләк уяту; ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, хәрәкәтләртөгәллеген үстерү;<br>3) кышкы табигатьнең матурлыгын күрә, соклана белүләренә шартлар тудыру. |
| | | Җ. Дәрзамановның «Алмаз» шигырен уку. | 1)Балаларны Җ. Дәрзамановның шигыре белән таныштыру, тәрбияченең сорауларына җавап бирергә күнектерү; җыр тыңлаганда актив булырга өйрәтү;<br>2) аңга алуларын, игътибарны, сүзлекне, му-зыкаль ишетү сәләтен үстерү;<br>3) дөрес киенергә теләк уяту, шигырьләр белән кызыксыну хисе тәрбияләү. |
| | | Ә. Бикчәнтәеваның «Салкын саф һава» шигырен ятлау. | 1) балаларны шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, кышкы табигать турындагы белемнәрен тирәнәйтү, шигъри текстны истә калдырырга ярдәм итү;<br>2) сәнгатьле сөйләмнәрен үстерү;<br>3) шигъри әсәргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| 01.02.-23.02.. | Ватанны саклаучылар көне | З. Туфайлованың «Шофер булам» дигән шигырен уку. | 1) балаларны шигырьнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирә белүләренә ирешү, сүзлекләрен баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын ,конкрет-образлы фикерләүләрен үстерү;<br>3) шофер хезмәтенә карата кызыксынуларын үстерү, юл йөрү кагыйдәләрен үтәргә кирәклеген төшендерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Ә.Исхакның «Гүзәл» шигырен уку. | 1) балаларны шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белергә өйрәтүне дәвам итү, тәрбияче сорауларынааңлы рәвештә җавап биру-ләренә, җырның сүзләренәтуры китереп, төгәл хәрәкәтләр ясауларына ирешү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда культура- гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| 24.02.- 08.03.. | Сигезенче Март | Д. Аппакованың «Рөстәм» әсәрен уку. | 1) чәчмә әсәрнең эчтәлеген аңлауларына, тәрбиячинең сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмнәрен үстерү;<br>3)табын әдәбе тәрбияләү. |
| | | «Чәбәк-чәбәк әбкәсе...» юаткычын уку | 1) балаларның юаткычны күрсәтмәлектән башка гына тыңлый белүләренә ирешү; истә калдыру максатыннан, юаткычның кайбер сүзләрен тәрбияче артыннан берничә тапкыр кабатларга мөмкинлек бирү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын; кул һәм гәүдә хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) татар халык аваз иҗаты белән кызыксыну, әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү. |
| | | З. Туфайловның «Әни сүзе» шигырен ятлау. | 1) балаларны шигырь белән таныштыру; истә калдыру максатыннан, тәрбияче биргән сорауларга шигырь сүзләре белән җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү, алардауңай эмоцияләр тудыру;<br>3) әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү. |
| | | Г. Нәбиуллинаның «Әнигә булышам» шигырен уку. | 1) балаларны Г.Нәбиуллинаның шигыребелән таныштыру, бире- лгән сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, диалогик сөйләмнәрен, кулларының вак моторикасын үстерү;<br>3) әниләргә ярдәм итү теләге, тырышлык, пөхтәлек тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 09.03.-31.03. | Халык җәүһәрләре | Л. Толстойның «Өч аю» әкиятенуку | 1) балалар өчен зур күләмле булган әкиятне игътибар белән тыңлауларына һәм аңлауларына ирешү; сәнгатьле сөйләм аша балаларда әдәби пер- сонажларның эш гамәлләренә бәя бирү, үзкичерешләрен чагылдыра белү күнекмәләре формалаштыра башлау; сүзлекне активлаштыру, балаларның сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;<br>3) әкиятләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Л. Толстойның «Өч аю» әкиятен сөйләү | 1) әсәрне кабаттан игътибар белән эчтәлегенаңлап тыңлауларына ирешү, башкаларның эмоциональ халәтен аңлый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>3) әйләнә-тирәдә үз- үзеңне тоту кагыйдәләре;җиһазга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | «Төлке, Куян һәм Әтәч» әкиятен сөйләү | 1) рус халык әкиятен балаларның исләренә төшерү; сюжетның үсешеартыннан күзәтергә, әкиятнең эчтәлеге буенчасорауларга җавап бирергәөйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, фикерләвен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда кеше хәленә керә белүчәнлек, кайгыртучанлык, ярдәмчеллек, бер-берсенә карата игътибарлылык, дуслык хисләре тәрбияләү. |
| 01.04.-20.04. | Яз | Д. Гарифуллинның «Тавыклар һәм Таһир» шигырен уку | 1) шигъри әсәр белән таныштыру; йорт кошлары турындагы белемнәрен тирәнәйтү; сорауларга аңлап, дөресҗавап бирүләренә ирешү; аваз ияртемнәре әйтелешен ныгыту; бер һәм күп төшенчәләрен ныгыту;<br>2) балаларның аңга алуларын, күзаллауларын,игътибарын, кул хәрәкәтләрен, иҗади сәләтләрен үстерү; фантазияләрен баету;<br>3) балаларда йорт кошларына карата кайгыртучанлык, үзләре башкарган эшкә шатлана белү хисләре тәрбияләү. |
| | | Р. Батулланың «Елак әтәч» әсәренуку | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, сорауларга дөрес һәм аңлап җавап бирүләренә ирешү; төрле орлыкларны (бодай, дөге) аера белергә өйрәтү;<br>2)балаларның аңга алуларын, игътибарын,кул чукларының вак мускулларын үстерү; яңа сүзләрне сөйләмдәактивлаштыру;<br>3)тешләрне саклау, алар турында кайгырту кирәклеген аңлауларына ирешү; культура- гигиена кагыйдәләре формалаштыру. |
| | | Б. Рәхмәтнең «Яз» шигырен | 1)балаларны Б. Рәхмәтнең «Яз» шигыре белән укып таныштыру, истәкалдырырга ярдәм итү; эчтәлегенә туры китереп,сорауларга җавап бирергәөйрәтү, яз турында белемнәрен баету; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ятлау | 2) балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, сөйләмнәренең сәнгатьлелеген үстерү;<br>3) шигырьдә сурәтләнгән язгы табигатькә карата кызыксыну, соклану хисе тәрбияләү. |
| | | Х.Вахитның «Уңган сыерчык» шигырен уку | 1) балаларны шигырь белән таныштыру, тәрбияче сорауларына шигырь сүзләре белән җавап бирүләрен ныгыту; музыка астында түгәрәктә бер-берсенә комачауламый йөри белүләрен формалаштыру; кошлар ту- рындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда туган якка мәхәббәт, җылы яктан кайткан кошларгакарата кызыксыну, мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү. |
| 02.05.-31.05. | Җәй | «Тилгән» эндәшенуку | 1) балаларның шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белүләренә ирешү; шигырьдәге аерым сүзләр һәм фразалар хисабына сүзлекләрен баету, шигырь сүзләренистә калдыруларына ирешү; кошлар (тилгән) турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, конкрет–образлы фикерләвен үстерү;<br>3) балаларның шигырьнедөрес интонация белән сөйләүләренә ирешү. |
| | | Мин җәйне яратам | 4) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдәкулланууларын активлаштыру, «бер», «күп» төшенчәләренныгыту;<br>5) балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, уңай хис-кичерешләрен, аңга алуларынүстерү;<br>6) табигатькә сакчыл караштәрбияләү. |
| | | «Аю белән хатын» әкиятен уку | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; сүзлекне баету, сөйләмдә активлаштыру. [З] авазын дөрес, ачыкәйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, аңга алуларын, фикерләүләренүстерү; чикләнгән пространствода йөгерергәөйрәтүне дәвам итү;<br>3)халык авыз иҗатына мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, кеше хәленә керә белүчәнлек хисләре тәрбияләү. |
| | | Ж. Тәрҗемановның «Кикри күк» шигырен уку. | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; тема буенча сүзлекләрен баету һәм активлаштыру, тәрбияче артыннан аерым фразаларны кабатларга һәм аваз ияртемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмнәрен, бармак хәрәкәтләрен үстерү; вакыт буенча (иртә-кич) ориентлашыргаөйрәтә башлау;<br>3) балаларда әдәби әсәргә кызыксыну тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | М. Мазуновның «Кәҗә» шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, сорауларга бәйләнешле итеп җавап бирергә, аваз ияртемен дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, фикерләвен, бәйләнешле сөйләмен, кул хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) йорт хайваннары белән кызыксыну, алар турында кайгыртучанлык тәрбияләү. |

3. Педагогик тикшерү буенча киңәшләр

Сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика биремнәр

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә?”

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба).

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары).

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары).

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар).

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**3 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: китап укучы әни, өрә торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Әни). Әни нәрсә эшли? (Укый). Әни нәрсә укый? (Әни китап укый).

Тәрбияче балага өрә торган эт төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Эт). Эт нәрсә эшли? (Эт өрә). Ул ничек өрә? (Эт һау-һау дип өрә).

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Малай). Малайның исеме ничек? (Бала малайга исем биреп карый). Малай нәрсә эшли? (Малай уйный). Ул нәрсә белән уйный? (Ул машина белән уйный).

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Кыз). Кызның исеме ничек? (Бала кызга исем биреп карый). Кыз нәрсә эшли? (Кыз рәсем ясый). Ул нәрсә белән рәсем ясый? (Ул карандаш белән рәсем ясый). Кыз нәрсә рәсеме ясый? (Кыз кояш рәсеме ясый).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?”

Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: - Бу нәрсә? (Ат). Ат ничек кешни? (Их-ха-ха). - Бу нәрсә? (Кәҗә). Кәҗә ничек кычкыра? (Ме-е-е). - Бу нәрсә? (Тавык). Тавык ничек кыткылдый? (Кыт-кыт). - Бу нәрсә? (Каз). Каз ничек каңгылдый? (Ка-ка-ка). - Бу нәрсә? (Карга). Карга ничек каркылдый ? (Кар-кар).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала 1-2 биремне генә үти ала.

**2 балл** – бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

**3 балл** – бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1). Сюжетлы картина буенча әңгәмә

Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы картинка.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

- Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер картинка ясаган. – Бу картинкада кем ясалган? – Балалар нәрсә эшлиләр? - Картинка сиңа ошыймы?

2). “Камыр малай” әкиятен сәхнәләштерү.

Тәрбияче өстәл театры фигуралары куллана, балаларга сәхнәләштерүдә катнашырга тәкъдим ясый.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә. Әкиятне сәхнәләштерүдә авырлыклар кичерә. Тәрбияче артыннан аерым сүзләрне генә кабатлый.

Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр әби белән

Бала: Бабай.

Тәрбияче: - Камыр малайны тәрәзә төбенә

Бала: Куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч, тәрәзәдән

Бала: Сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә урманга

Бала: Җитә.

**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә таныш әкиятне сәхнәләштерүдә катнаша.

Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр

Бала: әби белән бабай.

Тәрбияче: - Камыр малайны

Бала: Тәрәзә төбенә куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч,

Бала: Тәрәзәдән сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә

Бала: Урманга җитә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбиячenең үтенече буенча картинада сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклап сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

**Диагностик биремнәр**

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә?”

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә?  - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була?  (Савыт-саба). – Чәйнекнең борынын күрсәт. - Хәзер чәйнекнең капкачын күрсәт. – Чынаякның тоткасын күрсәт.

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (караваt, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары).  – Өстәлнең аякларын күрсәт. – Урындыкның аркасын күрсәт. – Шкафның ишеген күрсәт.

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә)  сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә?  - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары). - Этнең колакларын күрсәт. – Песинең койрыгын күрсәт. - Сыерның мөгезен күрсәт. - Кәҗәнең сакалын күрсәт.

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю)  сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: - Бу нәрсә?  - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар). – Куянның тәпиләрен күрсәт. – Төлкенең борынын күрсәт. – Аюның гәүдәсен күрсәт.

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык)  сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: - Бу нәрсә?  - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр). – Күлмәкнең җиңен (якасын, кесәләрен, сәдәфләрен) күрсәт.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен  атаганда һәм күрсәткәндә  авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес  атый, мөһим детальләрен, өлешләрен  күрсәткәндә, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**3 балл** – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен  дөрес атый һәм күрсәтә, гомумиләштерүче сүзләрне  дөрес билгели.

**“Бу кайчан була?” үстерелешле уены**

Балаларга тәүлек өлешләре сурәтләнгән карточкалар күрсәтелә. Тәрбияче тәүлек өлешенә туры килгән күренешләрне атый һәм сорау бирә, балалар тиешле карточканы табалар.

1. Кояш чыга, әтәчләр кычкыра, балалар бакчага барырга җыена, әти-әниләр эшкә китәләр. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы  табып күрсәтегез.

2. Кояш яктырак карый, күзләрен киңрәк ача, балалар урамда уйный, төшке аш ашыйлар. - Бу кайчан була?  Шушы тәүлек өлешенә туры килгән карточканы  табып күрсәтегез.

3. Кояшкүзләрен йома, балалар бакчадан, әти-әниләр эштән өйләренә кайта, кичке аш ашыйлар, балалар “Тыныч йокы, нәниләр” тапшыруын карыйлар. - Бу кайчан була?       Бу тәүлек өлешенә  туры килгән карточканы  табып күрсәтегез.

4. Кояш йоклый, ай яктырта, күк йөзендә йолдызлар яна,  бар кешеләр дә йоклый.       - Бу кайчан була?   Бу тәүлек өлешенә   туры килгән карточканы  табып күрсәтегез.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – тәүлек өлешләрен аера белми.

**2 балл** – өстәмә сораулар биргәндә генә тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

**3 балл** – тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: Йомшаккай уенчыгы, төрле кошлар һәм җәнлекләр сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балаларга Йомшаккай турында сөйли: “Безнең Йомшаккайның дуслары бик күп. Дусларының кем икәнен белергә телисезме? Ул аларның фотографияләрен алып килгән. (тәрбияче бер һәм күп куяннар, үрдәкләр, колыннар, чебиләр, көчекләр, сыерлар, бәрәннәр сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Бер куян сурәтләнгән картинка күрсәтә). (Куян). Бу нәрсә? (Куяннар сурәтләнгән картинка күрсәтә). (Куяннар). Башка картинкалар белән эш шушы рәвешле алып барыла.

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: “Йомшаккай кошлар һәм җәнлекләр белән качышлы уйнарга ярата. Сез күзләрегезне йомыгыз. Йомшаккай кача. (Тәрбияче Йомшаккайны шкаф артына (эченә, өстенә, астына, янына) качыра. Балалар күзләрен ачалар һәм Йомшаккайны эзлиләр һәм аның кайда качканын әйтәләр. Мәсәлән: “Йомшаккай шкаф артына качкан”.

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: “Җәнлекләр һәм кошларны әниләре эзләп килгән. Әйдәгез әниләренә аларны табарга булышыйк”. (Тавык сурәтләнгән картинка куела). Тавык (сыер, эт, ат, сарык, куян) нәрсәне алырга килгән? Тавык чебине алырга килде. (Шул рәвешле куян куян баласын, сыер бозавын, эт көчеген, сарык бәрәнен, ат колынын таба).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиясенең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячене сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячене сорауларына җавап биргәндә берлек һәм күплек сандагы исемнәрне, **бәйлек сүзләрне (эченә, өстенә, астына, янына),** кошлар һәм җәнлекләр, аларның балалары атамаларын сөйләмдә дөрес куллана, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячене сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик уен “Минем кебек әйт”

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага үзе әйткән сүзләрне игътибар белән тыңлап, нәкъ шулай итеп кабатларга куша һәм сорау бирә: “Бу сүзләрдә нинди аваз бар?” Тәрбияче, әле бер, әле икенче авазны аерып, сүзләрне я кычкырып, я тыныч тавыш белән, я пышылдап әйтә. Мәсәлән: “Минем кебек әйт”.

А: Аааалсу, ааат, кааз, боткааа.

Ә: Әәәәмир, мәәәк, кәәәҗәәә.

О: ооон, йооорт, ооонык, кооолын.

Ө: өөөй, өөөстәл, көөөзге, көөөймә.

У: ууурман, ууенчык, куууян, кууурчак.

Ү: үүүлән, үүүрдәк, күүүбәләк, үүүрмәкүүүч.

И: Иииинсаф, иииипиии, тииен, машииина, әниии.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала кирәкле авазны ишетми, күп сүзләрне дөрес интонация белән әйтми, хаталар ясый.

**2 балл** – бала күп сүзләрне дөрес кабатлый, дөрес интонация белән әйтә, тәрбияче ярдәме белән кирәкле авазны билгели ала.

**3 балл** – бала кирәкле авазны ишетә, кабатлый, аны мөстәкыйль рәвештә дөрес интонация белән әйтеп, авазны билгели ала.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1). Сораулар буенча әңгәмә. – Синең өйдә нинди уенчыкларың бар? Син алар белән ничек уйныйсың? Кем белән уйныйсың? жгщмщСюжетлы картина буенча әңгәмә

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала бер уенчыкны гына атый.

**2 балл** – бала уенчыкларны санап кына чыга.

**3 балл** – бала үзенең шәхси тәҗрибәсенә нигезләнеп 3-4 җөмләдән торган хикәя төзи.

2). Тәрбияче балага Л.Толстойның "Өч аю" әкиятен сөйләргә тәкъдим итә. – Син "Өч аю" әкиятен беләсеңме? Аны сөйлә әле.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала әкият эчтәлегенә кагылышлы кайбер сүзләрне генә әйтә ала.

**2 балл** – бала тәрбияче биргән сораулар ярдәмендә генә әкиятнең эчтәлеген сөйли.

**3 балл** – бала әкиятнең эчтәлеген мөстәкыйль сөйли ала.

**Югары дәрәҗә** - 15-18 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 11-14 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 7-10 балл

**"Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү" буенча баланың персональ картасы**

| Баланың исеме фамилиясе | Баланың сүзлек запасы | Сөйләмнең грамматик ягы | Сөйләмнең аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | Гомуми үсеш дәрәҗәсе | Индивидуаль эш өчен тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Кулланылган әдобият

1. Балачак аланы (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2011.
2. Балалар бакчасында татарча сөйләм устеру дәресләре (методик кулланма.) З.М. Зарипова, А.И. Касимова. - Казан 2010.
3. Бала бишеге-гомер ишеге (җентык). Ф.Зарипова... - Яр Чаллы. 2000.
4. Балалар бакчасы (хрестоматия). Ф.Ю. Юсупов.- Казан. 2003.
5. Бал бабай. З. М.Зарипова, И.М. Хәмитов. - Яр Чаллы. 2000.
6. Балалар бакчасында тарбия һәм белем биру (программа). К.В.Закирова...- Казан 2009.
7. Гелбакча (хрестоматия). Ф.О. Юсупов... - Казан. 1990.
8. Диагностика речевого развития дошкольников. (3-7 лет). О.С.У шакова, Е.М. Струнина. - Москва. 1999.
9. Иң гузал тел-туган тел (методик кулланма). М.Ф. Кашапова. - Казан. 2009.
10.Иң матур суз (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2000.
11. Иң татлы тел-туган тел (методик кулланма). М.Ф. Кашапова. - Казан. 2004.
12. Ижат баскычлары (методик ярдәмлек). Р. К.Шаехова, К.В.Закирова.- Казан. 2001.
13. Методика развития речи детей. А. М. Бородич.- Москва. 1981.
14. Материал к занятиям по развитию речи. Г.И. Подрезова.- Москва. 2006.
15. Раушан көзге (хрестоматия). Р. Ш. Халикова.- Казан. 1993.
16. Туган телдә сөйләшәбез (методик кулланма) 2-3яшь. Ф.В.М.Хәзратова. - Казан. 2012.
17.Туган телдә сөйләшәбез (методик кулланма) 3-4яшь. Ф.В.М.Хәзратова. - Казан. 2013.
18. Татар халык уеннары. Р. Ягьфэров. - Казан. 2002.
19. Татар халык табышмаклары. "Идел-йорт" нашрияте. - Яр Чаллы. 2000.
20. Уйный-уйный үсәбез (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2005.